ГЛАВА ЧЕМОДУРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.1а, с. Чемодурово,
423307

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЬ
ЧЕМОДУРОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ
Нагорная ур., 1нче йорт, Чемодурово
авылы, 423307

Тел./факс(885592)3-31-61; E-mail:Chmd.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2023 ел №1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының «2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатыннан Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының «2022 елга Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру юлы белән, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чемодурово авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлегенең ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының "Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең 2022 елгы бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (1нче кушымта)

2. Ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2022 елның 10 апрелендә 13.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны - 423307, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Чемодурово авылы, Нагорная урамы, 3А йорт;

- тикшерелгән мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча бирелә: 423307, ТР, Азнакай районы, Чемодурово авылы, Нагорная урамы, 1А.

4. Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Азнакай муниципаль районы Чемодуровский авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Чемодуровский авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең гамәлдәге законнары, норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда халык алдында тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге Советының "2022 елга Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын (1 нче кушымта) Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта (http//aznakayevo.tatarstan.ru), 2023 елның 16 мартыннан соңга калмыйча, урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Чемодурово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, 2023 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru// урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: А.П.Курганская